**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(III чакырылыш)**

**чиратган тыш утырыш**
**КАРАРЫ**

11 октябрь 2018 ел **№ 145** Теләче авылы

Теләче муниципаль районы территориясендә кулланучылар хокукларын яклау буенча чараларны оештыручы вәкаләтле орган турында

Муниципаль районның җирле үзидарә органнарының муниципаль районнарның җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә кертелмәгән мәсьәләларне хәл итү хокукын гамәлгә ашыру максатларында, "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында "Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында" 2018 елның 29 июлендәге 244-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, шәһәр, авыл җирлеге, муниципаль район, шәһәр округы, шәһәр эчендәге бүленеш булган шәһәр округы җирле үзидарә органнарының кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыруга хокуклары өлешендә", Теләче муниципаль районы Советы карары,

1. Теләче муниципаль районы территориясендә "Кулланучылар хокукларын яклау турында" 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә каралган, кулланучылар хокукларын яклау чараларын тормышка ашыруга җирле үзидарә органы вәкаләтле вәкил итеп Теләче муниципаль районы Башкарма комитетын билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетына бер ай эчендә җирле үзидарә органының «Кулланучылар хокукларын яклау турында " 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законы белән каралган Теләче муниципаль районы территориясендә кулланучылар хокукларын яклау буенча чаралар күрүгә вазыйфаи затын билгеләргә һәм вазыйфаи затның эш регламентын расларга.

3. Әлеге карарны Теләче муниципаль районының Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Теләче муниципаль
районы Башлыгы И.Ф. Зарипов